ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагаравыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Новоургагарского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

Адресы: 422870, ТР, Әлки районы, Иске
Үргәагар авылы, Г.Тукай урамы,
6 йорт, тел./факс 8(84346) 73-776

Адрес: 422870, РТ, Алькеевский
район, с. Старые Ургагары, ул.Г.Тукая. д.6
тел./факс 8(84346) 73-776

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 15 мае 7 №

Яңа Үргәагар авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге «2021-2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен уңай икътисади мохит формалаштыру максатында, Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге «2021-2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 9 номерлы карары (2021 елның 7 июнендәге ред.) белән расланган муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Программаны финанслау:

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга методик, консультация-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук җирле бюджет акчалары исәбеннән финанс, мәгълүмат һәм башка формалар алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатында түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сум)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга методик кулланмалар, мәгълүмат буклетлары, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Программа кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә:

Кушымта

«2021-2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» Программасының максаты һәм нәтиҗәсен бәяләү индикаторлары

| Төп чара исеме | Бурычларга туры килү | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максат: Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру, инновацион икътисадны формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының санын арттыру һәм көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итү, шулай ук аның җирлекнең социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә керткән өлешен арттыру | | | | | | | | |
| Республика һәм федераль бюджетлар акчаларыннан эшмәкәрлеккә ярдәм итү программалары буенча консультация ярдәме күрсәтү һәм мәгълүмат бирү | 3 | Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән консультацияләр саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары, аларны чишү юллары буенча анкета үткәрү | 4 | Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән анкеталар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен законнарның үзгәрүе һәм үсеше белән бәйле актуаль хокукый мәсьәләләр буенча, шулай ук эшкуарлыкка ярдәм итүнең гамәлдәге программалары буенча киңәшмәләр һәм семинарлар үткәрү; | 1 | Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән семинарлар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшьләр эшмәкәрлеге өлкәсенә җәлеп итү буенча яшьләр бергәлеге белән эшләү | 2 | Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга методик кулланмалар, мәгълүмат буклетлары, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

Яңа Үргәагар авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Рәхимҗанов Ә.Ә.